КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.07.2026 Казан шәһәре № 463-П

Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Вахитов районында урнашкан «Казан шәһәренең мәдәни катлавы-2» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясенең чикләрен һәм аннан файдалануның аерым режимын раслау турында

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты мәсьәләләре» 2018 елның 12 июлендәге 565 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Әлеге боерыкка 1 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Вахитов районында урнашкан «Казан шәһәренең мәдәни катлавы-2» мәдәни (археологик) мирас объектын ачыкланган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертергә.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

әлеге боерыкка 2 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Вахитов районында урнашкан «Казан шәһәренең мәдәни катлавы-2» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясе чикләрен;

әлеге боерыкка 3 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Вахитов районында урнашкан «Казан шәһәренең мәдәни катлавы-2» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясеннән файдалануның махсус режимын.

3. Мәдәни мирас объектларын исәпкә алу һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге бүлегенә күрсәтелгән ачыкланган мәдәни мирас объекты территориясе чикләре

турында белешмәләрне Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертүне тәэмин итәргә.


Рәис И.Н. Гущин

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас объектларын
саклау комитетының 2026 елның
22 июлендәге 463-П номерлы
боерыгына 1 нче кушымта

АЧЫКЛАНГАН МӘДӘНИ МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕНӘ КЕРТЕЛГӘН АРХЕОЛОГИК МИРАС ОБЪЕКТЫ

| | |
|---|---|
| Объектның исеме | «Казан шәһәренең мәдәни катлавы-2» |
| Урнашу урыны: | Һәйкәл Казан шәһәренең Вахитов районында, Нур Баян урамында, Идел елгасының сул ярындагы су басмасы өсте террасасында урнашкан. |
| Датировкасы: | XIX гасыр. Яңа заман. |

Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Вахитов районында урнашкан «Казан шәһәренең мәдәни катлавы-2» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты урнашу урынының вәзгыяти планы





Шартлы билгеләр:

- объектның урнашу урыны чикләре.

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас объектларын
саклау комитетының 2026 елның
22 июлендәге 463-П номерлы
боерыгына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Вахитов районында урнашкан «Казан шәһәренең мәдәни катлавы-2» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясе чикләре картасы (схемасы)




Шартлы билгеләр:

- объектның урнашу урыны чиге.

●1 - объект урнашкан урын чикләренең характерлы ноктасы.

Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Вахитов районында урнашкан «Казан шәһәренең мәдәни катлавы-2» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге

| Характерлы ноктаның билгесе (номеры) | Җирле координаталар системасында характерлы нокталарның координаталары (МСК 16 Зона 1) | | Бөтендөнья геодезия координаталар системасында характерлы нокталарның координаталары (WGS 84) | |
|---|---|---|---|---|
| | X | Y | N | E |
| 1 | 474352.82 | 1304952.71 | 55.776533344 | 49.110614197 |
| 2 | 474367.24 | 1304973.70 | 55.776662650 | 49.110948943 |
| 3 | 474366.54 | 1304974.40 | 55.776656356 | 49.110960086 |
| 4 | 474369.26 | 1304978.03 | 55.776680749 | 49.111017981 |
| 5 | 474370.13 | 1304982.77 | 55.776688516 | 49.111093532 |
| 6 | 474359.29 | 1304990.16 | 55.776591080 | 49.111211103 |
| 7 | 474361.04 | 1304992.45 | 55.776606775 | 49.111247627 |
| 8 | 474346.66 | 1305003.08 | 55.776477511 | 49.111416766 |
| 9 | 474347.04 | 1305003.58 | 55.776480919 | 49.111424741 |
| 10 | 474344.28 | 1305005.57 | 55.776456110 | 49.111456403 |
| 11 | 474341.30 | 1305007.73 | 55.776429323 | 49.111490771 |
| 12 | 474337.19 | 1305005.04 | 55.776392435 | 49.111447831 |
| 13 | 474335.28 | 1305003.79 | 55.776375293 | 49.111427877 |
| 14 | 474331.30 | 1304999.31 | 55.776339591 | 49.111356414 |
| 15 | 474325.53 | 1304989.48 | 55.776287865 | 49.111199664 |
| 16 | 474322.70 | 1304984.30 | 55.776262499 | 49.111117068 |
| 17 | 474319.85 | 1304977.68 | 55.776236968 | 49.111011524 |
| 18 | 474325.04 | 1304973.32 | 55.776283627 | 49.110942137 |
| 19 | 474335.73 | 1304965.77 | 55.776379716 | 49.110822013 |
| 20 | 474338.61 | 1304963.10 | 55.776405610 | 49.110779516 |
| 21 | 474352.54 | 1304952.30 | 55.776530833 | 49.110607658 |
| 1 | 474352.82 | 1304952.71 | 55.776533344 | 49.110614197 |

# Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Вахитов районында урнашкан «Казан шәһәренең мәдәни катлавы-2» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясе чикләренең текстлы тасвирламасы

Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Вахитов районында урнашкан «Казан шәһәренең мәдәни катлавы-2» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясе чикләре түбәндәгечә уза:

| Чик өлешләре турында белешмәләр | | |
|---|---|---|
| Чик өлешен билгеләү | | Чик өлешен узу тасвирламасы |
| ноктадан | ноктага кадәр | |
| 1 | 2 | төньяк-көнчыгышка таба (азимут 55°30.7`) 25,47 метр |
| 2 | 3 | көньяк-көнчыгышка таба (азимут 135°0.0`) 0,99 метр |
| 3 | 4 | төньяк-көнчыгышка таба (азимут 53°9.3`) 4,54 метр |
| 4 | 5 | көнчыгышка-төньяк-көнчыгышка (азимут 79°35.9`) 4,82 метр |
| 5 | 6 | көньяк-көнчыгышка таба (азимут 145°43.0`) 13,12 метр |
| 6 | 7 | төньяк-көнчыгышка таба (азимут 52°36.8`) 2,88 метр |
| 7 | 8 | көньяк-көнчыгышка таба (азимут 143°31.6`) 17,88 метр |
| 8 | 9 | төньяк-көнчыгышка таба (азимут 52°45.9`) 0,63 метр |
| 9 | 10 | көньяк-көнчыгышка таба (азимут 144°12.5`) 3,4 метр |
| 10 | 11 | көньяк-көнчыгышка таба (азимут 144°3.8`) 3,68 метр |
| 11 | 12 | көньякка-көньяк-көнбатышка таба (азимут 213°12.3`) 4,91 метр |
| 12 | 13 | көньякка-көньяк-көнбатышка таба (азимуты 213°12.2`) 2,28 метр |
| 13 | 14 | көньяк-көнбатышка таба (азимут 228°22.9`) 5,99 метр |
| 14 | 15 | көньяк-көнбатышка таба (азимут 239°35.3`) 11,4 метр |
| 15 | 16 | көнбатышка-көньяк-көнбатышка таба (азимут 241°21.1`) 5,9 метр |
| 16 | 17 | көнбатышка-көньяк-көнбатышка таба (азимуты 246°42.4`) 7,21 метр |
| 17 | 18 | төньяк-көнбатышка таба (азимут 319°58.0`) 6,78 метр |
| 18 | 19 | төньяк-көнбатышка таба (азимут 324°46.1`) 13,09 метр |
| 19 | 20 | төньяк-көнбатышка таба (азимут 317°10.0`) 3,93 метр |
| 20 | 21 | төньяк-көнбатышка таба (азимут 322°12.8`) 17,63 метр |
| 21 | 1 | төньяк-көнчыгышка таба (азимут 55°40.2`) 0,5 метр |

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас объектларын
саклау комитетының 2026 елның
22 июлендәге 463-П номерлы
боерыгына 3 нче кушымта

Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Вахитов районында урнашкан «Казан шәһәренең мәдәни катлавы-2» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясеннән файдалануның махсус режимы

Чикләрендә археологик мирас объекты урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның махсус режимы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы федераль законда (алга таба – 73-ФЗ номерлы федераль закон) билгеләнгән тәртиптә 73-ФЗ номерлы федераль законның 30 статьясында билгеләнгән археологик кыр эшләрен, җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләрен һәм ачыкланган археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү, шулай ук гражданнарның аннан файдалана алуын тәэмин итү шарты белән башка эшләрне уздыру мөмкинлеген күздә тота.

1. Түбәндәгеләр рөхсәт ителә:

мәдәни мирас объектларын саклауның федераль органы биргән рөхсәт (ачык кәгазь) нигезендә археологик мирас объектын өйрәнү эшләрен, археологик әйберләрне эзләү һәм алу максатын күздә тоткан эшләрне дә кертеп, үткәрү;

мондый эшләрне башкару проектларында яисә археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү проектларында яки уздырыла торган эшләрнең археологик мирас объектына йогынтысын бәяләүне үз эченә алган коткару археологик кыр эшләрен уздыру планында археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү турында, мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм саклау өлкәсендә вәкаләтле орган белән килештерелгән мәҗбүри бүлекләрне гамәлгә ашыру шарты белән, ачыкланган археологик мирас объекты территориясе чикләрендә урманнардан файдалану буенча 73-ФЗ номерлы федераль законның 30 статьясында күрсәтелгән эзләнү, проект, җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләрен һәм башка эшләрне башкару;

законнар нигезендә гражданнарның археологик мирас объектына үтеп керүен оештыру.

2. Түбәндәгеләр тыела:

мондый эшләрне башкару проектларында яисә археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү проектларында яки уздырыла торган эшләрнең археологик мирас объектына йогынтысын бәяләүне үз эченә алган коткару археологик кыр эшләрен уздыру планында археологик мирас объектының саклап калу, файдалану, популярлаштыру өлкәсендә вәкаләтле орган белән сакланышын тәэмин итү турында, мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм саклау өлкәсендә вәкаләтле орган белән килештерелгән мәҗбүри бүлекләрне гамәлгә ашырмыйча, ачыкланган археологик мирас объекты территориясе чикләрендә урманнардан файдалану буенча 73-ФЗ номерлы федераль

законның 30 статьясында күрсәтелгән эзләнү, проект, җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләрен һәм башка эшләрне башкару.